| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАЛТАСИНСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«13» август 2024 ел № 114

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕНДӘ ТЕРРИТОРИАЛЬ ИҖТИМАГЫЙ ҮЗИДАРӘ УСТАВЫН ТЕРКӘҮ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Советының «территориаль иҗтимагый үзидарә турында нигезләмәне раслау хакында " 2024 елның 12 августындагы 112 номерлы карарына таянып Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлегендә "Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» интернет-ресурсында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (baltasi.tatarstan.ru).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Советының Авыл хуҗалыгы, җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре , әйләнә-тирә мохитне саклау, чисталык, төзекләндерү, яшелләндерү буенча комиссиясенә йөкләргә.

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин

Балтач шәһәр җирлеге Советының
карарына кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕНДӘ ТЕРРИТОРИАЛЬ ИҖТИМАГЫЙ ҮЗИДАРӘ УСТАВЫН ТЕРКӘҮ ТӘРТИБЕ

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү тәртибе (алга таба – тәртип) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын юридик зат төземичә генә теркәү процедурасын регламентлаштыра. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә уставын (алга таба – ТИҮ уставы, җирлек) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге Советы (алга таба – җирлек Советы) терки.

2. ТИҮ уставын теркәү өчен территориаль иҗтимагый үзидарә төзү буенча гражданнар җыелышы яисә конференциясе (делегатлар җыелышы) тарафыннан ТИҮ уставын теркәү процедурасында катнашуга вәкаләт бирелгән зат (алга таба – ТИҮ вәкиле) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге башлыгына (алга таба – җирлек башлыгы) түбәндәге документлар тапшырыла:: 1) гражданнар җыелышының яисә конференциясенең (делегатлар җыелышының)барлык вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган ТИҮ уставын теркәү турында гариза; 2) Территориаль иҗтимагый үзидарә төзү турында Карар кабул ителгән гражданнар җыелышының яисә конференциясенең (делегатлар җыелышының) беркетмәсе, анда һәр вәкаләтле вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясе, номеры һәм аны бирү датасы, яшәү урыны адресы күрсәтелгән; 3) ТИҮ уставы (ике нөсхәдә). Теркәлүгә җибәрелә торган ТИҮ уставы ТИҮ вәкиле имзасы белән расланырга, номерланырга, таныкланырга тиеш. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән документлар җирлек Советы Аппаратында теркәлә.

3. Документларны кабул итеп алганда ТИҮ вәкиленә әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән документларны алуга исемлек һәм аларны алу датасы әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада каралган форма буенча күрсәтелеп, расписка бирелә. ТИҮ вәкиле гражданнар җыелышы яисә конференциясе (делегатлар җыелышы) карары белән ТИҮ уставын җирлек Советы тарафыннан теркәлгәнче теләсә кайсы этапта кире алырга хокуклы.

4. Җирлек советы җирлек башлыгы тарафыннан әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән документлар алынган көннән алып 30 көн эчендә ТИҮ уставын теркәү турында яисә мондый теркәүдән баш тарту турында дәлилле карар кабул итә. ТИҮ уставын теркәү турында Карар кабул ителгән очракта ТИҮ вәкиленә ТИҮ уставын теркәү турында әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтадагы форма буенча таныклык бирелә. ТИҮ уставы теркәлгән очракта, уставның бер нөсхәсе аны теркәү турындагы тамга белән ТИҮ вәкиленә тапшырыла, икенче нөсхә җирлек Советы аппаратында саклана.

5. ТИҮ вәкиле ТИҮ уставын теркәү (теркәүдән баш тарту) турында тиешле территориядә яшәүчеләргә хәбәр итәргә тиеш.

6. ТИҮ уставын теркәүдән баш тартуга карата суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

7. ТИҮ уставын теркәүдән баш тарту, кире кагуга китергән нигезләр бетерелгән очракта, документларны теркәүгә кабат тапшыру өчен киртә булып тормый.

8. ТИҮ уставына кертелә торган үзгәрешләр ТИҮ уставын теркәүнең җирлек Уставында һәм әлеге Тәртиптә билгеләнгән тәртибенә охшаш тәртиптә теркәлергә тиеш.

9. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитеты (алга таба – җирлек башкарма комитеты) әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтада каралган форма буенча Балтач шәһәр җирлеге территориаль иҗтимагый үзидарәләре уставлары реестрын (алга таба – уставлар реестрын) алып бара, аңа җирлек территориясендә гамәлдә булган барлык территориаль иҗтимагый үзидарәләр, шул исәптән юридик зат буларак теркәлгән территориаль иҗтимагый үзидарәләр кертелә.

10. Уставлар реестрына кертү өчен юридик зат буларак теркәлгән территориаль иҗтимагый үзидарә җирлекнең башкарма комитетына ТИҮ Уставының күчермәсен һәм аның җитәкче органы турында белешмәләрне, шул исәптән җитәкче турында белешмәләрне дә, тапшыра.

11. ТИҮләрне теркәү (ТИҮ уставына үзгәрешләр кертү) өчен бирелә торган документлар җирлек Советы Аппаратында 5 ел саклана, шуннан соң Башкарма комитетның архив бүлегенә тапшырыла